**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 октябрендәге 3529 номерлы карары**

## Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 7295 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:16:120601:1862, 16:16:000000:10393, 16:16:120601:14697, 16:16:120601:14698, 16:16:000000:6153;

- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы – 16:16:120601;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы, «Фотон» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте;

- билгеләү максаты: алга таба файдалану өчен «Газүткәргечнең коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте чигенә кадәр тармаклануы. Адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, «Фотон» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте» газ белән тәэмин итү объектын төзү;

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округы Генераль планы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 16 апрелендәге 484 номерлы «РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ КАЙБЕР АКТЛАРЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА»гы карары нигезендә коммерцияле булмаган

бакчачылык ширкәтләрен газлаштыру программасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ тарату челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 3 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1. пунктчасында күрсәтелгән 16:16:120601:1862, 16:16:000000:10393, 16:16:120601:14697, 16:16:120601:14698, 16:16:000000:6153 кадастр номерлы җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;

7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү буенча эшләр тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларда каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин


итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 15 октябрендәге
3529 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




| | |
|---|---|
| Масштаб: 1:7000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| 16:16:120601 | кадастр кварталы |
| 16:16:120601:1862, 16:16:000000:10393, 16:16:120601:14697, 16:16:120601:14698, 16:16:000000:6153 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________________